РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

04.12.2019 №1664-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 23 гыйнварындагы 64-п номерлы карары белән расланган 2017-2020 елларга “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2014-2022 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү “Дәүләт программасын раслау турында” 2014 елның 30 апрелендәге 289 номерлы карарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “2017-2020 елларга “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү “муниципаль программасын раслау турында” гы 2017 елның 23 гыйнварындагы №64-п номерлы карарына (Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 13 июлендәге 1046-п номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

– исемендә, карарның 1 пунктында “2017-2020 еллар” сүзләрен “2017 - 2022 еллар” сүзләренә алмаштырырга;

– Карар преамбуласында “2014 - 2021 елларга” сүзләрен “2014 - 2022 елларга” сүзләренә алмаштырырга;

**2.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “2017-2020 елларга “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү “муниципаль программасын раслау турында”гы 2017 елның 23 гыйнварындагы №64-п номерлы карары белән расланган 2017-2020 елларга “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” муниципаль программасына (Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 13 июлендәге 1046-п номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр редакциясендә) (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**2.1.** Программа исемендә “2017-2020 еллар” сүзләрен “2017 - 2022 еллар” сүзләренә алмаштырырга;

**2.2.** Программа паспорты таблицасында:

а) “Программа исеме” юлында “2017-2020 еллар” сүзләрен “2017 - 2022 еллар” сүзләренә алмаштырырга;

б) “Программаны эшләү өчен нигезләр” юлында “2014 - 2021 елларга” сүзләрен “2014 - 2022 елларга” сүзләренә алмаштырырга;

**2.3.** Программаның 1 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“I. Программаның максатлары, бурычлары, принциплары
һәм аны гамәлгә ашыру сроклары.

Программа гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу яки индивидуаль торак йорт төзү өчен дәүләт ярдәме системасын үстерүне күздә тота.

Программаның максаты-торак проблемаларын хәл итүдә социаль түләүләр бирү юлы белән торак шартларын билгеләнгән тәртиптә яхшыртуга мохтаҗ дип танылган яшь гаиләләргә өстәмә дәүләт ярдәме чаралары күрсәтү.

Программаның бурычлары:

стандарт торак сатып алу яки стандарт индивидуаль торак йорт төзү (алга таба – социаль түләүләр) өчен Программада катнашучыларга - яшь гаиләләргә социаль түләүләр бирүне тәэмин итү;

яшь гаиләләрнең үз акчаларын, банкларның һәм башка оешмаларның, шул исәптән Ипотека торак кредитлары һәм шәхси торак сатып алу яки төзү өчен кредитлар һәм заемнар бирүче оешмаларның финанс чараларын җәлеп итү өчен шартлар тудыру.

Яшь гаиләләр – программада катнашучылар стандарт торак алу өчен вәкаләтле оешмаларга мөрәҗәгать итә алалар.

Программаны тормышка ашыруның төп принциплары булып тора:

яшь гаиләләрнең программада катнашу теләге;

закон нигезендә яшь гаиләне торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тану;

яшь гаиләнең торак өчен исәп-хисап (уртача) бәясен социаль түләү күләменнән артып киткән өлешендә түләү өчен җитәрлек акча булуы;

яшь гаиләләр өчен программа кысаларында федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирле бюджеттан торак шартларын яхшыртуга бирелә торган акчалар хисабына ярдәм алу хокукын 1 тапкыр гына гамәлгә ашыру мөмкинлеге бар. Программаны гамәлгә ашыру срогы - 2014 - 2022 еллар.”;

**2.4.** Программаның 2 бүлегенең икенче абзацында “2014 - 2021 елларга” сүзләрен “2014 - 2022 елларга” сүзләренә алмаштырырга;

**2.5**. Программаның 4 бүлегендә

- Өченче абзацта “2014 - 2021 елларга” сүзләрен “2014 - 2022 елларга” сүзләренә алмаштырырга;

**2.6**. программага 1 нче кушымтада:

– 1 пунктның 1 абзацында “2014 – 2021 елларга” сүзләрен “2014 – 2022 елларга” сүзләренә алмаштырырга;

– 1 пунктның беренче абзацын “;өлешләп төзү объекты буларак торак бинаны күздә тоткан, эскроу счетына тиешле акчалар кертү юлы белән, өлешле төзелештә катнашу килешүе бәясен түләү (алга таба – өлешләп төзүдә катнашу килешүе бәясен түләү)” сүзләре белән тулыландырырга;

– 6 пунктның беренче абзацында “җирле үзидарә органнары тарафыннан танылган” сүзләрен “программада катнашу өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан танылган” сүзләренә алмаштырырга;

– 15 пунктны түбәндәге эчтәлекле ж) пункты белән тулыландырырга:

– “ж) гаиләнең һәр балигъ булган әгъзасына индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ күчермәсе.”;

– 16 пунктның беренче абзацында 15 пунктның “б” – “г”, “е” пунктчалары нигезендә” сүзләрен 15 пунктның “б”- “г”, “е” һәм “ж” пунктчалары нигезендә” сүзләренә алмаштырырга;

28 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“28. Җирле үзидарә органы Татарстан Республикасы бюджетыннан социаль түләүләр бирү өчен билгеләнгән субсидияләрне бирүгә каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары турында хәбәр алганнан соң биш эш көне дәвамында хәбәр итү фактын һәм датасын расларга мөмкинлек бирә торган ысул белән яшь гаиләләргә - социаль түләү алуга дәгъва кылучыларга таныклык алу өчен документлар тапшыру кирәклеге турында хәбәр җибәрә, шулай ук әлеге таныклык буенча бирелә торган социаль түләүне алу һәм куллану тәртибен һәм шартларын аңлата.

Социаль түләү алуга хокук турында таныклык алу өчен яшь гаилә - тиешле елда социаль түләүгә дәгъва кылучы, социаль түләүгә хокук турында таныклык алу өчен документлар тапшыру кирәклеге турында хәбәрнамә алганнан соң 15 эш көне эчендә, мондый таныклык (ирекле рәвештә) бирү турында гариза һәм әлеге Кагыйдәләрнең 2 кушымтадасында күрсәтелгән документларны даими яшәү урыны буенча җирле үзидарә органына җибәрә.

Гаризада яшь гаилә, мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән тәртиптә һәм шартларда социаль түләү алуга язмача ризалык бирә.

Саба муниципаль районы Башкарма комитеты әлеге документлардагы мәгълүматларны тикшерү эшен оештыра.”;

**2.7.** 30 пунктның б) подпунктында “аларны” сүзен “аны” сүзенә алмаштырырга;

**2.8.** 2017-2022 елларга “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” программасы кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләренә 1 кушымтаны яңа редакциядә әлеге карарга 1 кушымта нигезендә бирергә.

**2.9.** 2017-2022 елларга “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” муниципаль программасы кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләренә 2 кушымтаның 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“10) гаиләнең һәр балигъ булган әгъзасының индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ күчермәсе;”;

**2.10**. 2017-2022 елларга “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” муниципаль программасы кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләренә 3 кушымтаны әлеге карарга 2 кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

**3**. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

**4.** Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы И. Р. Гариповка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы,
инвестицион үсеш һәм эшкуарлыкка ярдәм итү буенча
Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары - Саба
муниципаль районының инвестицион үсеш һәм
эшкуарлыкка ярдәм итү бүлеге башлыгы И. И. Котдусов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 4 декабрендә кабул ителгән 1664-п номерлы карарына
1 кушымта

2017-2022 елларга “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” программасы кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алу өчен социаль түләүләр бирү кагыйдәләренә
1 кушымта

(Якынча формасы)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иҗтимагый торак комиссиясе рәисенә

_______________________________________

_______________________________________

____________________________________нан

(Ф.И.АИ.)

ГАРИЗА

Сорыйм Сездән безне торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тануны һәм яшь гаиләмне “Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү” Россия Федерациясе дәүләт программасының “Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” ярдәмче программасы һәм “2014 - 2022 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү” дәүләт программасының “2014 - 2022 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” ярдәмче программасында (алга таба - Подпрограмма) катнашучылар составына түбәндәге составта кертүегезне:

ире ____________________________________________________________________,

(Ф.И.АИ., (булган очракта) туу вакыты)

паспорт сериясе ____________№ __________,___________________________________

___________________________________________________________________________

«___»____________________бирелгән,_________________________________________

_____________________________________________________________адресы буенча яши;

хатыны ________________________________________________________________,

(Ф.И.АИ., (булган очракта) туу вакыты)

паспорт сериясе ____________№ __________,___________________________________

___________________________________________________________________________

«___» ___________________ бирелгән,_________________________________________

_____________________________________________________________адресы буенча яши

балалар: ________________________________________________________________,
(Ф.И.АИ., (булган очракта) туу вакыты)
Туу турында таныклык (14 яше тулган бала өчен паспорт)
(кирәкмәгәнен сызып ташларга)
серия _________ № _________, ________________________________________
_____________________________________________________________________________
«___» ____________________бирелгән,_______________________________
____________________________________________________адресы буенча яши
балалар: _______________________________________________________________
(Ф.И.АИ., (булган очракта) туу вакыты)
Туу турында таныклык (14 яше тулган бала өчен паспорт)
(кирәкмәгәнен сызып ташларга)
серия ___________№ _________,_____________________________________________
_____________________________________________________________________________
"__" _______________________бирелгән,___________________________________
_____________________________________________________адресы буенча яши

Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:
1) ________________________________________________________________;
(документның исеме, датасы,номеры һәм кем тарафыннан бирелгән)
2) ________________________________________________________________;
(документның исеме, датасы,номеры һәм кем тарафыннан бирелгән
3) ________________________________________________________________;
(документның исеме, датасы,номеры һәм кем тарафыннан бирелгән)
4) ________________________________________________________________;
(документның исеме, датасы,номеры һәм кем тарафыннан бирелгән)
5) ________________________________________________________________;
(документның исеме, датасы,номеры һәм кем тарафыннан бирелгән
6) ________________________________________________________________;
(документның исеме, датасы,номеры һәм кем тарафыннан бирелгән
7) ________________________________________________________________;
документның исеме, датасы,номеры һәм кем тарафыннан бирелгән)
8) ________________________________________________________________;
документның исеме, датасы,номеры һәм кем тарафыннан бирелгән
9) ________________________________________________________________.
(документның исеме, датасы,номеры һәм кем тарафыннан бирелгән)

“2014 - 2021 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 21 пункты нигезендә, мохтаҗлыкны һәм түләүгә сәләтлелекне раслау өчен (ярдәмче программага 3 кушымта), планлаштырыла торган елга кадәрге елның 1 августына кадәр һәм планлаштырыла торган елда социаль түләүләр алуга дәгъва кылучы яшь гаиләләр исемлегенә кертелгәндә ел саен бирелә торган документлар тапшыру кирәклеге турында хәбәр ителде.

“Россия Федерациясе гражданнарын һәркем өчен мөмкин булган һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү” Россия Федерациясе дәүләт программасының “Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” төп чарасында катнашу шартлары белән таныштым һәм аларны үтәргә сүз бирәм:

“Россия Федерациясе гражданнарын арзан һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү” Россия Федерациясе дәүләт программасының “торак белән тәэмин итүдә һәм торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә гражданнарга

дәүләт ярдәме күрсәтү” ведомство максатчан программасының яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү чарасында катнашу шартлары белән һәм республика дәүләт программасы белән таныштым  һәм аларны үтәргә сүз бирәм.

Дөрес булмаган мәгълүмат биргән очракта, программада катнашучы яшь гаиләләр исемлегеннән төшереп калдыру мөмкинлеге турында хәбәрдар.

“Шәхси мәгълүматлар турында” 2006 елның 27 июлендәге №152-ФЗ Россия Федерациясе Законы таләпләрен үтәп, шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәм.

1) ________________________________________ _____________ ______________;
(Ф.И.АИ. (булган очракта) гаиләнең балигъ булган әгъзасы )  (имза)  (дата)

2) ________________________________________ _____________ ______________;
(Ф.И.АИ. (булган очракта) гаиләнең балигъ булган әгъзасы )  (имза)  (дата)

Гариза һәм аңа исемлек буенча кушып бирелгән документлар кабул ителде:
«____» ____________ 20__ ел.

_________________________________ _________________ ______________
(гариза кабул иткән зат вазыйфасы)  (дата, имза)  (имзаның тулы бирелеше)

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2019 елның 4
декабрендә кабул ителгән
1664-п номерлы карарына
2 кушымта

2017-2022 елларга “Татарстан
Республикасы Саба муниципаль
районында яшь гаиләләрне торак
белән тәэмин итү” программасы
кысаларында яшь гаиләләргә
торак сатып алу өчен социаль
түләүләр бирү кагыйдәләренә
3 кушымта

(Якынча формасы)

РАСЛЫЙМ
Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башкарма комитеты
җитәкчесе, Саба муниципаль районы
Иҗтимагый торак комиссиясе рәисе
________________________
(Комиссия җитәкчесенең Ф.И.АИ.,
имзасы)
«____»_____________ 20 ____ ел.

**“Россия Федерациясе гражданнарын һәркем өчен мөмкин булган һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү” Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләрне торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тану (танымау) турында карар**

_________ яшь гаиләсе 2019 елның________________________________сәгатьтә, аны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тану турында гариза биргән.

Яшь гаилә әгъзаларының торак белән тәэмин ителеше:

| № п/п | Туганлык мөнәсәбәт ләре | Ф.И.АИ. | Биләгән гомуми мәйданы (кв. м, адрес) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | милек хокукында | социаль наем шартнамәсе буенча | теркәлү урыны буенча | барлы гы |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Гаилә әгъзаларының торак шартларын бәяләү нигезендә____________________ гаиләсен “Россия Федерациясе гражданнарын һәркем өчен мөмкин булган һәм уңайлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү” Россия Федерациясе дәүләт программасының “Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” ярдәмче программасы һәм Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү «ярдәмче программасы һәм “2014-2022 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү” дәүләт

программасының “2014-2022 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү” ярдәмче программасы кысаларында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаилә дип танылды/танылмады һәм 2017-2022 елларга “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” муниципаль программасында катнашучылар исемлегенә кертелде (кертелмәде).

Комиссия әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| ________________________ | ____________ | ______________ |
| (вазыйфаның исеме) | (имза) | (имзаның тулы бирелеше) |
| ________________________ | ____________ | ______________ |
| (вазыйфаның исеме) | (имза) | (имзаның тулы бирелеше |
| ________________________ | ____________ | ______________ |
| (вазыйфаның исеме) | (имза) | (имзаның тулы бирелеше |
| ________________________ | ____________ | ______________ |
| (вазыйфаның исеме) | (имза) | (имзаның тулы бирелеше) |

«____» _________________ 20 ____ ел.

Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы,
инвестицион үсеш һәм эшкуарлыкка ярдәм итү буенча
Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары - Саба
муниципаль районының инвестицион үсеш һәм
эшкуарлыкка ярдәм итү бүлеге башлыгы И. И. Котдусов